**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**

**Азнакай шәһәре** **№281-38** **«20» август 2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 23.05.2019 ел, №258-36 «Азнакай муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» карары белән расланган, «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ, «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлеге, «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният Идарәсе» МКУ Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлеге җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 23.05.2019 ел, №258-36 «Азнакай муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» карары белән расланган, «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МКУ, «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлеге, «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният Идарәсе» МКУ Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлеге җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«Хезмәт күрсәтү зоналарын киңәйтү һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча булмаган хезмәткәрнең вазыйфаларын башкарган өчен, хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонд кысаларында төп эш буенча вазыйфаи окладның 50 проценты күләмендә, белгечләргә өстәмә түләү билгеләргә».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин